**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Об отмене карантина, установленного на территориях некоторых населенных пунктов Республики Татарстан и на отдельной территории Рыбно-Слободского района Республики Татарстан в связи с их неблагополучием по заболеванию бешенством животных

В связи с истечением двух месяцев со дня последнего случая заболевания животных бешенством и выполнением противоэпизоотических и профилактических мероприятий, в соответствии со статьей $3^1$ Закона Российской Федерации от 14 мая 1993 года № 4979-I «О ветеринарии» **постановляю**:

1. Отменить карантин, установленный в связи с неблагополучием по заболеванию бешенством животных:

а) на территориях следующих населенных пунктов Республики Татарстан:

деревня Юкале Альметьевского района;

село Нижние Шитцы Сабинского района;

б) на территории улицы Советская в поселке городского типа Рыбная Слобода Рыбно-Слободского района Республики Татарстан.

2. Признать утратившим силу Указ Президента Республики Татарстан от 1 ноября 2018 года № УП-761 «Об установлении карантина на территориях некоторых населенных пунктов Республики Татарстан и на отдельной территории Рыбно-Слободского района Республики Татарстан в связи с их неблагополучием по заболеванию бешенством животных».

3. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Исполняющий обязанности**
**Президента Республики Татарстан** **А.В. Песошин**

Казань, Кремль
04 января 2019 года
№ УП-1

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе районының аерым территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле урнаштырылган карантинны бетерү турында**

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерергә:

а) Татарстан Республикасының түбәндәге торак пунктлары территорияләрендә:

Әлмәт районының Юкәле авылы;

Саба районының Түбән Шытсу авылы;

б) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе районының Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогының Совет урамы территориясендә.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2018 елның 1 ноябрендәге ПУ-761 номерлы Указы үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын башкаручы** **А.В. Песошин**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2019 ел, 04 гыйнвар
№ ПУ-1